| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан Карашай-Сакловское сельское поселение Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге** |

---

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 21 август 2017 ел | **№ 46** |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Сарман муниципаль районының «Карашай-Саклау авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.3 өлешен, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указының 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Карашай-Саклау авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Карашай-Саклау авыл җирлеге
Советы рәисе В.В.Хосниева